**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 август № 556

г. Казань

Шәһәр яны элемтәсендә халыкка автомобиль транспорты белән (җиңел таксидан гайре) транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 ел, 28 апрель, ТРЗ-32 нче Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Шәһәр яны элемтәсендә халыкка автомобиль транспорты белән (җиңел таксидан гайре) транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын (карарга теркәлә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар формаларын раслау хакында» 2010 ел, 25 ноябрь, 934 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 август, 556 нчы карары белән расланды

Форма

**Шәһәр яны элемтәсендә халыкка автомобиль транспорты белән (җиңел таксидан гайре) транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап**

______________________________________________________________

(җирле үзидарә органы исеме)

| Шәһәр яны элемтәсендә халыкка автомобиль транспорты белән транспорт хезмәте күрсәтү күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | План | Факт |
|---|---|---|---|
| Маршрутлар саны | берәмлек | | |
| Маршрут челтәре ераклыгы | километр | | |
| Рейслар саны | берәмлек | | |
| Йөртелгән пассажирлар күләме | мең кеше | | |
| Пассажирлар йөртү әйләнеше | млн.пассажир-километр | | |
| Күчмә состав саны | берәмлек | | |
| Даими автобус элемтәсе булган торак пунктлар саны | берәмлек | | |

______________________________________